РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 12 » ноябрь 2019 ел № 39

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль
берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш
Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча
ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы берәмлеге «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 27.11.2006 ел №22-1карары белән расланган, ТР Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- мәйданы 18501,0 кв. м. булган, 16:02:060303:375, 16:02:060303:376 кадастр номерлы, ТР, Азнакай муниципаль районы, Туйкә авыл җирлеге адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны С12 махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасыннан һәм авыл хуҗалыгы җирләре (СХУ) җирләреннән авыл хуҗалыгы (СХ1) билгеләнешендәге объектлар зонасына үзгәртергә;

мәйданы 4784,0 кв.м. булган, 16:02:060301:223 кадастр номерлы,ТР, Азнакай муниципаль районы, Туйкә авылы, Ленин урамы, 22 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны Ж1 шәхси торак төзелеше зонасыннан СХ1авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасына үзгәртергә.

2. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын оештыручы - Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре проектын әзерләү буенча комиссиясе;

- уздыру вакыты-2019 елның 15 ноябреннән 2019 елның 16 декабренә, 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны-Туйкә авылы, Гагарин урамы, 4А йорт, Туйкә авылы мәдәният йорты;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2019 елның 15 декабренә кадәр – Туйкә авылы, Җәлил урамы, 19 нчы йорт адресы буенча, Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетына кертелә ала.

4. Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлауларны үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.//. Веб-адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Закирова Р.Р.